РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.04.2018 №80-п

Саба муниципаль районы
Башлыгының аерым карарлары
көчен югалткан дип тану турында

Саба муниципаль районы норматив-хокукый базасын тәртипкә китерү максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

Түбәндәге карарларны көчен югалткан дип таныргa:

1) Саба муниципаль районы Башлыгының “Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне дәүләт кадастр бәяләве эшенең үтәлеше барышын һәм нәтиҗәләрен карау, шулай ук килештерү бәхәсле булган эш нәтиҗәләрен муниципаль район дәрәҗәсендә хәл итү буенча ведомствоара комиссия төзү турында” 20.10.2006 ел 94-п номерлы карарын;

2) Саба муниципаль районы Башлыгының “Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясенең составын һәм Нигезләмәсен раслау турында” 01.02.2011 ел 10-п номерлы карарын;

3) Саба муниципаль районы Башлыгының “Саба муниципаль районының кризиска каршы штабын төзү турында” 04.02.2015 ел 14-п номерлы карарын;

4) Саба муниципаль районы Башлыгының “Саба муниципаль районында агач материалын законсыз хәзерләү, ташу, эшкәртү, сату һәм чит илгә чыгаруны кисәтү һәм чик кую мәсьәләләре буенча комиссия турында” 25.05.2012 ел 38-п номерлы;

5) Саба муниципаль районы Башлыгының “Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләләре буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе төзү турында” 26.05.2007 ел 59-п номерлы карарын;

6) Саба муниципаль районы Башлыгының "Саба муниципаль районы Советының эш башкару кагыйдәләрен һәм эшләр номенклатурасын эшләү комиссиясе турында" 04.02.2015 ел 13-п номерлы карарын;

7) Саба муниципаль районы Башлыгының "Саба муниципаль районының идарәче кадрлары резервын булдыруны тәэмин итү чаралары планын эшләү буенча эшче төркем төзү турында" 29.12.2008 ел 173-п номерлы карарын;

8) Саба муниципаль районы Башлыгының "Муниципаль район һәм башкарма хакимиятнең территориаль органнары вәкилләренең координация советы турында" 29.11.2006 ел 107-п карарын;

9) Саба муниципаль районы Башлыгының "Саба муниципаль районында «Мәгариф» өстенлекле милли проекты буенча Совет төзү турында" 14.05.2008 ел 54-п номерлы карарын.

Саба муниципаль
районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов